Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР

КАРАР

25.02.2022 ел Менделеевск ш. №109

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач һәм Бөрешле авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач һәм Бөрешле авыл җирлекләре территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасын һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районын территориаль планлаштыру схемалары белән расланган комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы һәм Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемаларында федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган булуга бәйле рәвештә

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач һәм Бөрешле авыл җирлекләренең генераль планнарын эшләүдә ихтыяҗ булмавын танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының икътисад, сәнәгать, ТКХ, төзелеш һәм элемтә мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К.Галиева